ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» июнь 2020 ел № 176

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклану мәсьәләләрен җайга салу комиссиясен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 мартындагы 86 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрешләре белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклану мәсьәләләрен җайга салу комиссиясен раслау турында» 2020 елның 16 мартындагы 86 номерлы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклану мәсьәләләрен җайга салу комиссиясе составыннан - Макаров Валерий Владимировичны төшереп калдырырга;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклану мәсьәләләрен җайга салу комиссиясе составына комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы-Вәлиев Азат Рөстәм улын кертергә.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) “Документлар” бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **А.Р. Вәлиев**